**Һәр җир карланган,**
**Сулар бозланган,**
**Уйный җил-буран,**
**Бу кайчак, туган?**

***Кыш  көне***

# КЫШ



**Шома табанлы чана**
**Атсыз да алга чаба-**
**Җитез булса аяклар,**
**Кулда була таяклар.**
**Бар бер чана**
**Утырасы юк,**
**Бассаң-үзе чаба.**

ЧАҢГЫ

**Төсен үзгәртми бер дә,**

**Гел яшел күлмәк кия.**

**Матур бизәнеп, һәр елны**

**Безгә кунакка килә.**

**Нәрсә ул?**

*чыршы*

**Тышта ыжгырып**
**Җил-буран дулый,**
**Күзеңне ачып**
**Карап та булмый.**

*буранда*

**Җәй тукылдый бу чүкеч,**
**Кыш тукылдый бу чүкеч,**
**Ничек чыдый бу чүкеч?**

***Тукран***

**Кыш кар күп булса,**

**җәй яңгырлы булыр.**

*КЫШ-ҖӘЙ*

**Чанада да шуабыз,**

**Чаңгыда да шуабыз.**

**Тимераякта очабыз,**

**Чыжлап тора шома боз.**

*чанада, чаңгыда,тимераякта, боз*

# Бу нәрсә?



**Ишегалды таш була,**
**Өйгә керсә, су була.**

**БОЗ**

«Кыш рәхәт ***чанага,***

җәй рәхәт ***арбага***”

**Безгә Кыш бабай килгән,**

**Яңа ел алып килгән.**

**Капчыгына күп итеп**

**Бүләкләр салып килгән.**

**Кыш бабай, Яңа ел, капчыгына, бүләкләр**

Унбишенче декабрь.
Сыйныф эше.

# Өй эше.

«5» ле –исемнәрне кулланып Кыш бабайга хат язарга

«4»ле -дустыңа Яңа ел теләкләре

«3»ле- күнегү